КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 31 март г.Казань № 295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының администра-тив үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче; 2019 ел, 21 май, 427 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче; 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы; 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы; 2020 ел, 1 апрель, 248 нче; 2020 ел, 27 май, 428 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль

районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан В.П.Кандиловны, Н.В.Кондратованы чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Социаль-икътисадый мониторинг департаменты башлыгы Роман Дамир улы Әмирхановны;

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Равил Рәид улы Сираҗиевны;

Илнур Мәхмүт улы Гариповның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин